№2, Октябрь 2025

# Чишмә башы

МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”

**Бу санда:**

- *Күзге мәрхәмәтлек атнасы*
- *Хәйрия ярминкәсе*
- *Әтиләр көне*
- *Юлда да акыл кирәк*
- *Күз бәйрәме*
- *Ял сәгатьләрендә*



**Сынамышлар**

- Көз озын килсә, яз соң килер.
- Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
- Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.
- Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.
- Көз көне кошлар түбән очса, кыш – салкын, югары очса, кыш җылы килә.
- Көз көне куяннар бер эздән йөрсә, кыш көне кар күп явар.

## Көзге мәрхәмәтлелек атнасы

6 нчы октябрьдән 20 нче октябрьгә кадәр Татарстанда “Көзге мәрхәмәтлелек атнасы” республика акциясе үтте. Акция ел саен дөньяның күп илләрендә, шул исәптән Россиядә дә үткәрелә. Безнең мәктәп тә читтә калмады.

Атна кысаларында бик күп яхшы гамәлләр башкарылды. Мәсәлән, спортның файдасы турында төрле чаралар һәм әңгәмәләр, "Солдатка хат" һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар



ярдәм җыю акцияләре, хәйрия ярминкәсе, волонтерлар турында әңгәмәләр, укучылар Бөек Ватан сугышы ветераннары турында фотоальбом төзеделәр, мәктәп территориясен җыештыру буенча көзге өмә оештырдылар.

Игелеклелек кылып кемнедер шатландыруың белән үзең дә сөенечле хисләр кичерәсең, күңел канәгатьләнүе дә аласың. Мондый чаралар олыларга ихтирам хисен арттыра, ярдәмчел булырга, бердәмлеккә өйрәтә, күмәк эшкә өнди.

## Хәйрия ярминкәсе

17 октябрьдә безнең мәктәптә махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм йөзеннән көзге ярминкә узды. Ярминкәдә мәктәбебезнең барлык укучылары һәм укытучылары катнашты. Барысы да сугышчыларга – СВОда катнашучыларга ярдәм итәргә теләделәр.



Ярминкәне әзерләүдә барлык укучылар һәм, әлбәттә, аларның әти-әниләре ярдәм итте. Килүчеләрнең һәркайсы үзенә ошаган товарларны – символик суммага сатып ала алды. Алынган акчалар Россия хәрби хезмәткәрләре өчен беренче ихтыяҗ товарларын сатып алуга барачак.

Мәктәп администрациясе барлык укучыларга һәм ата-аналарга хәйрия акциясен оештыруда һәм уздыруда ярдәм иткән өчен зур рәхмәт белдерә!

## Әтиләр көне




19 октябрьдә без искиткеч бәйрәм – Әтиләр көнен билгеләп үттек. Бу үзенчәлекле көн, балалар үзләренең яраткан әтиләре һәм бабайларына чын күңелдән мәхәббәтләрен һәм ихтирамнарын белдерделәр! Бу бәйрәм хөрмәтеннән мәктәпләрдә әңгәмәләр үткәрелде. Укучылар әтиләре һәм бабайлары турында сөйләделәр. Дәреснең мөһим өлеше котлау открыткалары ясау булды.
Шулай ук мәктәп укучылары “Әти белән эштә” акциясендә катнаштылар.

## Юлда да акыл кирәк

22 октябрь көнне мәктәбебездә 3,4 класс укучылары катнашында "Юлда да акыл кирәк" темасына мероприятие узды. Мероприятиенең максаты: юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрне ныгыту, урамда йөргәндә игътибарлы булырга өйрәтү, машина йөртүче, юл хәрәкәтен көйләүче хезмәткәр һөнәрләренә кызыксыну тәрбияләү. Чарада Арча районы буенча ЮХИДИнең "ЮХИ" бүлеге житәкчесе Мөхәмәтҗанова Энҗе Газизовна катнашты.



## Көз бәйрәме






Безнең мәктәптә традицион бәйрәмнәрнең берсе – Көз бәйрәме узды, анда 1-9 сыйныф укучылары катнашты. Укучылар буяулы стенгазеталар чыгардылар.

Мәктәптәге көз бәйрәме – ул матур һәм истә калырлык чара. Барлык балалар өчен дә үзләренең иҗади сәләтләрен күрсәтү, кызыклы чыгышлар ясау, дуслар арасында ял итү өчен менә дигән мөмкинлек.

Программа бәйгеләрне, көзге җырларны, биюләрне үз эченә алды. Чара күңелле һәм дустанә шартларда узды. Балалар бик күп уңай хис-кичерешләр генә түгел, яхшы кәеф тә алдылар.







## Ял сәгатьләрендә




| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Е | Б | У | Е | Н | О | Л | У | Н | К | В | У |
| Ч | А | Р | Г | А | П | Ь | Ф | Т | И | И | Д |
| Ш | Ш | К | А | Е | О | Д | Ю | Ш | О | С | Я |
| А | П | Л | Я | Л | П | У | Н | А | Л | А | Ш |
| Э | О | К | К | Н | И | Х | Р | А | А | Ш | Д |
| Н | Д | К | А | Н | И | Й | А | Ш | М | Е | Ж |
| А | И | Ш | В | И | Ц | К | Б | И | Р | Р | И |
| Н | Т | О | И | Ф | А | О | П | А | У | Г | Л |
| К | А | О | Н | Б | Е | Л | Ш | Т | А | М | Ш |
| Л | Р | Б | У | Н | К | М | Е | Ы | О | М | О |
| С | О | Н | Л | Т | И | Ә | М | Ч | Т | К | Р |




Рәсемнәрдә сурәтләнгән мультфильм персонажларының исемнәрен башваткычтан табыгыз. Кызыл төстәге хәрефләрне буш шакмакларга дөрес итеп язсагыз, мультипликация белән бәйле профессия исеме килеп чыгар.




| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| З | Ж | К | О | Г | Е | Ы | Н | О | Ю |
| Р | И | О | Д | Ө | З | Р | А | Б | Л |
| А | К | Р | И | М | Б | О | Р | Ы | С |
| Ф | П | А | Л | О | А | Р | Л | А | Н |
| Г | Л | Н | Д | А | К | Ы | С | Б | Ү |
| Е | П | Т | Ө | Я | У | Б | О | Е | Р |
| Р | А | К | Л | Н | О | Я | Л | А | Н |
| Д | З | Е | А | Ю | Д | Ө | Г | А | И |
| Б | Е | А | Й | Я | Ф | И | К | Т | Е |
| Р | А | М | М | Ы | Л | Л | Е | Р | П |




Рәсемнәрдә сурәтләнгән хайваннарның исемнәрен башваткычтан табыгыз. Бер сүз билгеләп куелган инде. Артып калган хәрефләрне буш шакмакларга дөрес язсагыз, хайваннар дөньясын өйрәнүче фән исеме килеп чыгар.

**Сәхифәне әзерләде:** химия, биология һәм география укытучысы Гарифуллина Г.Д.
**Корректорлар:** туган тел һәм әдәбияты укытучылары Садриева Н.З., Юнысова Р.К.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт

**Социаль челтәр бите:** https://vk.com/77arsk_srkorsa

**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru